**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ТАШКИЧҮ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
**КАРАР**

**23.05. 2015 ел** **Кече Урыссу ав.** **№ 9**

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы
Ташкичү авыл җирлеге Советының 2014 елның 18
ноябрендәге “Җир салымы турында”гы 21 санлы
карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлегенең 387 маддәсе II өлешенә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичүй авыл җирлеге Советы карар итә:

1 нче маддә

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Советының 2014 елның 18 ноябрендәге “Җир салымы турында”гы 21 санлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.3 маддәдә " салым ташламалары»:

1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.Кадастр бәясеннән ташламалы салым ставкасын:

1) Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм җирле бюджеттан финанслана торган казна, автоном, бюджет учреждениеләре, идарә органнары тарафыннан биләнгән һәм салым салу объектлары дип танылган җир кишәрлекләренә карата 0,2% ;

2) 1-3 категорияле гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү һәм эксплуатацияләү өчен бирелә торган җир участокларына карата 0,05%.

2 нче маддә

Әлеге карар мәгълүмат стендында рәсми рәвештә игълан ителгән һәм Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылган көннән үз көченә керә. Россия Федерациясе Салым кодексының I өлешендәге 5 маддәсенең 3 һәм 4 пунктларына ярашлы рәвештә, 2015 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Ташкичү авыл җирлеге башлыгы: Р.К.Вәлиев.